РАСЛЫЙМ:
Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгүт авыл җирлеге Башлыгы, җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру буенча эшче төркем рәисе

________________ И.А.Вильданов

«  18  »   ноябрь     2024 ел

**Җир кишәрлеген файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карар проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгүт авыл җирлегенең 2024 елның 21 октябрендәге 10 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгүт авыл җирлеге кадастр номеры булган 16:02:040101:809,1460 кв.м мәйданы булган җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты (Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгының карар проекты) Азнакай муниципаль районы Мәсгүт авыл җирлеге Мәсгүт авылы Баһманов урамы 18 – “Яшелчәлек алып бару” Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Мәсгүт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәхси торак төзелеше зонасында (Ж1) җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (алга таба карар проекты) рөхсәт бирү турында гавами тыңлауларны билгеләү хакында”гы карары буенча гавами тыңлаулар үткәрелде.

Үткәрү вакыты: 2024 елның 30 октябреннән 2024 елның 12 ноябренә кадәр.

Гавами тыңлауларны оештыручы - җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру буенча эшче төркем.

Гавами тыңлауларны уздыру турында мәгълүмат: Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районы Мәсгүт авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә урнаштыру юлы белән игълан ителде.

Җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт сорала торган җир кишәрлеге белән уртак чикләре булган җир кишәрлекләренең хокук ияләренә хәбәр итү: җир кишәрлеге белән уртак чикләре булган җир кишәрлекләре юк.

2024 елның 30 октябреннән 2024 елның 12 ноябренә кадәр Мәсгүт авыл җирлеге Башкарма комитетында һәм Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлегендә гражданнардан һәм вазыйфаи затлардан язма рәвештә карар проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кабул ителде, шулай ук экспозициягә килүчеләрне исәпкә алу китабында (журналында) да теркәү алып барылды.

Гавами тыңлауларны уздыру вакыты, урыны һәм формасы: 2024 елның 13 ноябрендә мәскәү вакыты буенча 16.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: Татарстан

Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Мәсгут авыл җирлеге, Дуслык урамы, 12 Үткәрү рәвеше - җыелыш, эшче төркем әгъзалары 4 кеше катнашты.

2024 елның 13 ноябрендәге гавами тыңлауларның беркетмәсе Азнакай муниципаль районы Мәсәгут авыд җирлеге Башкарма теркәлгән.

Гавами тыңлауларны үткәрү барышында 2024 елның 30 октябреннән 2024 елның 12 ноябренә кадәр авыл җирлеге халкыннан әлеге карар проекты буенча җәмәгать фикер алышулары хакында тәкъдимнәр һәм искәрмәләр теркәлмәде.

Җыелыш үткәрү барышында 2024 елның 13 ноябрендә авыл җирлеге халкыннан карар проекты хакында түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Мәсгүт авыл җирлеге, Дуслык урамы, 12 язма рәвештә тәкъдимнәр һәм искәрмәләр теркәлмәде.

Гавами тыңлаулар материалларын карау нәтиҗәсендә түбәндәгеләр билгеләнде: гавами тыңлаулар уздыру тәртибе һәм процедурасы үтәлде һәм Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары таләпләренә туры килә.

**<u>Гавами тыңлауларны уздыру буенча эшче төркем нәтиҗәләре:</u>**

1. Гавами тыңлауларны уткәрелгән дип танырга.
2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгүт авыл җирлегенең 2024 елның 21 октябрендәге 10 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгүт авыл җирлеге кадастр номеры булган 16:02:040101:809,1460 кв.м мәйданы булган җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты (Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгының карар проекты) Азнакай муниципаль районы Мәсгүт авыл җирлеге Мәсгүт авылы Баһманов урамы 18 – “Яшелчәлек алып бару” Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Мәсгүт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәхси торак төзелеше зонасында (Ж1) җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (алга таба карар проекты) рөхсәт бирү турында гавами тыңлауларны билгеләү хакында”гы карар проектын хупларга.
3. Гавами тыңлаулар материалларын (беркетмәне, бәяләмәне) Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү буенча Комиссиясенә җибәрергә.
4. Җир кишәрлеген файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карар проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмәне Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районы Мәсгүт авыл җирлеге мәгълүмат стендында, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

Эшче төркем секретаре ______________________ А.М.Сергеева

Эшче төркем әгъзалары

_____________________ Р.Р. Әюпова

_____________________ Н.Г. Сабирҗанов